№7 (07) март, 2018 ел 1
ҖИР ЙӨЗЕНДӘ ТЫНЫЧЛЫК, ДУСЛЫК, МӘРХӘМӘТЛЕЛЕК, ГАДЕЛЛЕК БУЛСЫН!

# ХЫЯЛ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ РАЙОНЫ
“ЧАЛМАНАРАТ ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ”НЕҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ

## Март аена истәлекле даталар

**1 – Наркоманиягә һәм наркобизнеска каршы халыкара көрәш көне.**
**Бөтендөнья гражданлык оборонасы көне.**
**8 – Халыкара хатын-кызлар көне.**
**21 – Нәүруз бәйрәме.**
**27 – Халыкара театр көне.**
**Россия эчке гаскәрләре көне.**
**30 – Җирне саклау көне.**

### Наркомания – кешелекнең дошманы.

Бер секундлык, бер минутлык ләззәт
Юлдаш булмасын ул беркемгә.
Матур гына башланган бу уен
Китерәчәк безне үлемгә.
Гомерләрнең шушы матур чагын
Үткәрәсе иде бәхеттә.
Ал кулыңа тупны, чык урамга,
Карама ул шомлы эфьюнга.
Гомер дәфтәреңнең ап-ак битен
Син кара тап белән буяма.
Үтсен гомерең үрнәк гомер булып,
Начар гадәтләргә карама.

### Халыкара театр көне.

Театр халкыбызның рухын ныгыта, теленә, гореф - гадәтенә мәхәббәт уята. Төрле халыклар арасында дуслыкны арттыра, берләштерә. 1961 нче елдан билгеләнә башлый.



## ФӘНИС ЯРУЛЛИН. “РӘНҖЕМӘСЕН”

Тезелешеп очкан кыр казлары
Чагылып китсә әгәр офыкта
Кемдер карый кулын кашына куеп
Кемдер – бармак салып курокка
Кош-кортларга кемдер җимнәр куя
Һәм ышыклый зәһәр суыктан
Ә кемнәрдер читлек элеп куя
Үре каты тимерчыбыктан
Кемдер чишмәләрнең юлын ача
Ә кемнәрдер китә томалап
Дөнья бит бу, ә дөньяда инде
Төрле хәлләр тора булгалап.

Табигать ул үзен яклый алмый
Үч тә ала алмый кешедән.
Ул бары тик рәнҗи генә ала
Куркыйк шушы рәнҗеш төшүдән.
Рәнҗемәсен безгә очар кошлар
Рәнҗемәсен күлләр, урманнар
Рәнҗемәсен кояш, җир һәм күкләр
Рәнҗемәсен безгә ал таңнар.
Рәнҗемәсен , үзенең яклаучысы
Кеше иканлеген белсен ул.
Яңгырлары белән еласын да
Кояшлары белән көлсен ул.

| | | | |
|---|---|---|---|
| <br>Айзилә Хәбирова | **“Туган ягыбыз киңлекләре” фотоконкурсы**<br>**I урын** | <br>Сәйдәш Шакиров | **"Мәржани эзләре буйлап" әдәби викторинада**<br>**Җиңүче** |
| <br>Энже Вәлиева,<br>Айзилә Хәбирова | **“Без бергә” конкурсы**<br>**II урын** | <br>Манихова Адилә | **"Живая классика" конкурсында**<br>**Призёр** |
| <br>Яхин Имиль | **“Без бергә” конкурсында -**<br>**сертификат**<br>**XIX Халыкара “Чикләрсез балачак” фестивале**<br>**II урын** | <br>Басыйров Фидан | **XIX Халыкара “Чикләрсез балачак” фестивале**<br>**I урын** |
| **“Зарница” хәрби-спорт уены** | | | |
|  | **Автомат сүтеп җыю бәйгесендә Р.Гайсин, Д.Акбулатова, С.Имамов, М.Фазлыева**<br>**I урын** | **Пневматик винтовкадан ату ярышында Р.Р.Гайсин, Ф.Ф.Басыйров, Ф.Д.Гәрәев, С.В.Имамов, М.А.Фазлыева**<br>**II урын** | **Отжимание бәйгесендә Л.Галимова, Д.Насертдинова, М.Фазлыева**<br>**I урын** |

Булдыклы кеше таштан икмәк чыгарыр.
Тырышлык - зурлык, ялкаулык – хурлык.
Тырыштым - таудан аштым.
Физкультура - это залог успеха и здоровой жизни.

**Район, республика күләмендә урын алган һәм актив катнашкан егет, кызларны, аларны әзерләгән укытучыларыбыз Раушания апа Галимҗанова, Әлфия апа Исрафилова, Марат абый Гыйльметдиновны котлыйбыз! Киләчәктә дә уңышлар юлдаш булсын иде.**

**Ш.Ш.Булатов.**

## Балаларны яратам

Мин бүген сыйныф җитәкчесе
Ярты сүздән аңлыйм аларны.
Йөрәк тавышларын тыңлыйм
Бик яратам мин балаларны.

Күз карашларыннан тоямын
Һәммәсенең борчу, шатлыгын.
Йөрәгем аша үткәрәм,
Әйтәсе сүзләрен аларның.

Ашкынып барамын мәктәпкә,
Күрергә дип тизрәк аларны.
Алар белән янып яшим,
Бик яратам мин балаларны.

## Мәктәбем

Мәктәбем – хезмәт урыным
Һәр урыны якын күңелгә.
Мирза абый нигез салган
Аңа хөрмәт яши күңелдә.
Бай тарихлы мәктәбем
85 ел элек ачылган.
Башлангыч, җиде, сигезьеллык,
Урта мәктәп тә булган.
Хәзерге мәктәпнең бинасы
76 да салынган.
58 нче елдан башлап,
Директоры Мирза абый булган.

Күчмә Кызыл Байрак иясе
Чалманарат мәктәбем.
32 ел үзем дә
Данлы мәктәптә эшләдем.
Җиде укучының берсе
Алтын медаль иясе.
6 сы көмеш медальгә лаек,
5 се кызыл аттестат иясе.
Сәнгатьтә дә, спортта да
Алдынгылыкны бирми.
Иҗат өлкәсендә дә
Калышасыбыз килми.

## Әҗәкүлем

Туган илнең иркен күкрәгендә
Әҗәкүлем – туган җирем бар.
Авыр чакта кайтып сыенырга
Авылкаем - Әҗәкүлем бар.
Туган җирем – авылкаем синдә
Тәүге кабат аваз салганмын.
Табигатеңнән шифа алганмын,
Яшәү көче синдә тапканмын.
Хәзер синдә яшәмәсәм дә мин
Күз алдымнан һич тә китмисең.
Ашкынып, сагынып кайтам сине
Авылкаем, йөрәгемдә яшисең.
Яланыңда җәяү чапкан җилне
Килә һәрчак минем кочасым.
Агыйделеңдә, күлләреңдә
Килә һәрчак су коенасым.
Су өстендә уйнап йөгерешкән
Кояш нурларына карыймын.
Күзләремне камаштырган чакта
Гүя үткәнеңне барлыймын.
Мәчетең, училищең, заводың,
Пекарняң, тегермәнең, пристанең
Синең горурлыгың булганнар.
Яшьләр җылы оя корганнар.

Ап-ак пароходның тавышларын
Ишетер идем тагын мин синдә.
Юк шул, алар ерак калды
Хәзер күрәм аларны бары төшемдә.
Яшел чирәмеңдә уйнап үскән
Шагыйрәң, судьяң да бар синең.
Галим булган Камил улың да
Горурлыгың, авылым минем.
Җырга, моңга гашыйк авыл халкы
Алдынгылыкны бер дә бирмәгән.
Авырлыкларга бирешмәгән
Горур булган, башын имәгән.
Йомшак җилләр сыйпап уза
торган
Кылганлы яланыңнан узамын.
Синдә, бары синдә генә мин
Үземне бәхетле тоямын.
Туган җирем – алтын җирем
Яшәү бишегем минем.
Бишегеңдә тибрәнеп үскән
Нәни кызчыгың мин синең.
Яшә, авылым, мең яшә,
Яшә гомер-гомергә.
Һәр урының яши минем
Йөрәгемнең түрендә

Ә.Р.Исрафилова
Татар теле һәм әдәбияты укытучысы



КҮҢЕЛЛЕ СТАРТЛАР

КИТАП АТНАЛЫГЫ











6, 7, 8 нче класс укучылары һәм әниләре белән “Якты кояшым – әнием!” темасына кичә уздырылды. Җырлар тыңлау, кызыклы сорауларга җавап эзләү, уеннар белән үрелеп барган кичә әниләребез һәм үзебезне балачакка “алып кайтты”.

Кичәне уздырган класс җитәкчебез Әлфия апа Исрафиловага рәхмәтебезне белдерәбез.

Кызларны, әниләрне, апаларны, сеңелләрне бәйрәмнәре белән котлыйбыз.

С.С.Шакиров.

# Ял сәгатьләрендә

**Алты дус сәфәргә чыкканнар.**

Юлда ашарбыз дип биштәрләренә биш кабартма салганнар. Күпмедер баргач, сәяхәтчеләр ял итәргә туктаган.

- Кабартмаларны барыбызга да тигез бүләргә кирәк, - дигән берсе.
- Баш ватасы юк, һәр кабатрманы алтышар кисәккә бүлеп чыгыйк, - дигән икенчесе.
- Әйдә, алайса, үзең бүл, - диештеләр калганнар.

Камил биш кабартманы тип-тигез итеп алты өлешкә бүлеп куйды.
Әйтегез әле, ул ничек бүлде икән?

«Хыял» Чалманарат төп гомуми белем бирү укучыларының фәнни-популяр, әдәби-нәфис айлык басмасы
Шеф-мөхәррир: Диана Акбулатова Җаваплы сәркатип: Миләүшә Фазлыева Фотохәбәрче: Сәйдәш Шакиров
Безнең адрес: 423752, Чалманарат авылы, Мәктәп ур., 7 нче йорт. E-mail: Schal.Akt@edu.tatar.ru, chalm.akt@yandex.ru Тираж: 15 данә Кул куелды: 09.00; 31.03.2018
Мәктәп компьютерында басылды. Бәясе ирекле. Мәкаләдәге фикерләр өчен мөхәррият җавап тотмый.